Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге Салкын чишмә авылында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2019 елның 23 ноябре № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлегенең Салкын чишмә авылында гражданнар җыены **КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1.2020 елда, беренче төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Салкын чишмә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2.Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Салкын чишмә авылының Чапаев урамы юлына вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү).

3. Әлеге карарны Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru веб адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Ютазы муниципаль районының http://jutaza.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга .

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Кәрәкәшле авыл җирлеге Башлыгы Г.М.Хәмидуллина